Республика Татарстан

Совет Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 3 ноябреннән Менделеевск ш. №8

Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларга, контроль-хисап органы рәисенә айлык акчалата түләү күләмен, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен арттыру турында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисе, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары нигезендә «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында»

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Менделеевск муниципаль районы Советының 2018 елның 17 апрелендәге 142 номерлы карары белән расланган даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларны, контроль-хисап органы рәисен айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга «Депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, муниципаль хезмәткәрләрнең, Менделеевск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында».

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең үз биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә аларның вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2020 елның 1 октябреннән

2016 елның 17 апрелендәге 142 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә арттырырга «Депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, муниципаль хезмәткәрләрнең, Менделеевск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында».

3. Әлеге карарның 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләп чыгару өчен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладгы күләмен 1,03 тапкырга индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Менделеевск муниципаль районы» рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында htpp://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Совет Рәисе В.С.Чершинцев